

Китап яманлыктан яхшылыкны аерырга ойрәтә. Телсезләргә телләр бирә, койсезләрне койләтә. Вождан, намус, акыл биргән китап. Китапханә киштәсе саекмасын, аксын белем чишмәсе!

Белгәнебезчә, 27 майда китапха-нәчеләр коне. Быел аны зурлап тантаналы рәвештә Хокvмәтнен Русс драма театры бинасында vтә. Бик матур олы артистларнын концерты белгечләрнен кvнеленә хуш килә. Кызыклы республикабыз китапханәчеләрнен ачык Форумы А.С.Пушкин исемендәге Милли китапханәдә vтә. Чара кысаларында vткәрелгән тvгәрәк остәлдә Кадошкино районы Латышовка авылы китапханәсе житәкчесе Н.М. Байчурина коллегалары белән милли китап белән эшләv буенча эш тәжрибәсе белән уртаклаша. Татар язучыларынын китапларын бу авылда бvген дә бик теләп укыйлар. Нәкъ китапханәче матбугат олкәсендәге яналыкларны укучыга житкерә дә, татар матур әдәбият vрнәкләрен халыкка житкерә. Надия Мансур кызынын бу олкәдә тәжрибәсе зур, коллегалары анын кинәшләрен кызыксындырган. Шуна Латышовка авылы китапханәсе базасында район чарасы vткәрергә булганнар. Кадошкино районы китапханәчеләрен профессиональ бәйрәмнәре белән котларга «Бердәм Россия бvлеге» житәк-чесе Г.К.Хансвярова килгән. Галия Камил кызы, башка партия активистлары белән бергә, алдынгы китапханәче Н.М. Байчуринага да бvләген тапшырды. Хормәтле кунаклар арасында актив китап укучылары да бәйрәм белән котларга килгәннәр. Е.Ю.Кузнецова кырык биш ел бу китапханәгә йори. Ул мәктәпкәчә яшьтән ук китап ярата, бvген дә Елена Юрьевна яраткан дусты - китап белән аерылмый. Китапханәнен шундый дуслары байтак. Тик яшьләрне, интернет заманында, ничек тә китап – белем чишмәсе белән дус булу алымнарынын унышлыларын кулланып эш итәргә киректер. Чонки китапханәче профессиясе китап яратучыларны берләштерә дә.